СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с. Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Апаз авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**“30” октябрь 2023 ел** **№ 1**

**Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Кзыл-Игенче авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Апаз авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Кзыл-Игенче авылында Кзыл-Игенче авылы, Дальняя урамы, 3 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 13 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2024 елда Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Кзыл-Игенче авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 3000 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- Кзыл-Игенче авылының Дальняя урамыннан Пөшәңгәр авылының Нагорная урамына кадәрге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлын ташлы балчык, вак таш җәеп тигезләү, дүртенче этабы;

- Кзыл-Игенче авылының Дальняя урамында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю;

- янгынга каршы ёмкость сатып алу һәм урнаштыру?

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

3. Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Кзыл-Игенче авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Апаз авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Кзыл-Игенче авылы, Дальняя урамы, 16 йорты адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов